АЗЫК ҮЗӘКЛӘРЕ: уңай тәҗрибә нигә аз кулланыла?

> 2

БӘЙРӘМ КӨТКӘНДӘ Халык Яңа елдан могҗиза өмет итә

> 2

КУРЧАКЛАР ДӨНЬЯСЫНДА Рәйдә Ильинаның кул эшләре горурлык хисләре уята

> 4

ЙӘГЕЗ, БЕР ДОГА Салават Фәтхетдинов танылган шәхесләр рухына Коръән укытты

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 173 (28755) | Шимбә | 27 ноябрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

ПАНДЕМИЯ НӘРСӘ БЕЛӘН ҮЛЧӘНӘ?

Вазгыять

Республика клиник хастаханәсе «таҗлы» чорда кислород кулланыны алты тапкыр арттырган. Элегрәк тәүлегенә 1 тонна кислород файдаланганнар. Башкаланың 7 нче хастаханәсендә дә хәлләр шул чама – көненә 5–6 тонна кислород тотыла. Пандемиягә кадәр 500 кг булган. Хәлләрнең шәптән булмавын шушы саннар раслыйдыр кебек тә, тик...

«Татар-информ»

«Кызыл зона»да депутатларны көтәләр. Билгеле, сырхау буларак түгел. Шушы көннәрдә Россиянең әйдәп баручы баш табиблары коронавирус белән көрәшкә бәйле сәясәткә каршы кешеләргә ачык хат-мөрәҗәгать белән чыкты. Адресатлар – эстраданың танылган шәхесләре, җәмәгать эшлеклеләре һәм сәясәтчеләрнең күпчелеге – вакцина ясатуга, QR-код системасына каршы. Гомумән, коронавирус барлыгын инкарь итүчеләр дә бар. «Эш белән мәшгуль булсак та, сезне күпме кеше укыганын, караганын һәм тыңлаганын исәпкә алып, без сезне хастаханәләребезнең «кызыл зона»лары буенча йөртергә вакыт табарга әзер. Бәлки, шуннан соң фикерегез үзгәрер, кешеләр дә азрак үлә башламасмы. Көтеп калабыз!» – диелә мөрәҗәгатьтә.

Әлеге фикергә Татарстан табиблары да кушылды. Дәүләт Советы депутатлары Россия Хөкүмәтенең ил күләмендә җәмәгать урыннары һәм транспортта QR-код системасын кертү турындагы закон проектын хуплады. Каршы килүчеләр арасында ЛДПР, «Гадел Россия», КПРФ вәкилләре бар иде. Татарстанның сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков «Реальное время» интернет-басмасына интервьюсында: «Каршы тавыш биргән һәркемне «кызыл зона»да эшләп карарга чакырачакбыз», – дигән.

Аның урынбасары Владимир Жаворонков белдергәнчә, медицина тармагы мондый «экскурсияләр» оештырырга әзер. Кем әйтмешли, чир барлыгы, вазгыять киеренкелегенә ышанмаучылардан «гаризалар» кабул ителә.

Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе башлыгы урынбасары Любовь Авдонина хәбәр иткәнчә, әлегә вазгыять чикләү чараларыннан баш тартырга мөмкинлек бирми. Авыручыларның күп өлеше өлкәннәргә туры килә. Белгечләрне шул сагайта. 60 яшьтән өлкәнрәкләр арасында чир йоктыручылар күрсәткеченең 30 проценттан кимегәне юк. Үлем-китем очраклары да 4 мәртәбә артыграк.

Владимир Жаворонков исә алгы сафта булган медицина хезмәткәрләренең хәле турында сөйләде. Үзгәреш юк: алар әле дә алны-ялны белми эшли. «Авыр хезмәт» һәм «медицина хезмәткәре» синоним сүзләргә әйләнеп бара инде. Катлаулы шартларга түзә алмыйча эштән китүчеләр дә бар. Әйтик, эшкә яңа тотынучы яшь хезмәттәшләребез. Шуны аңласак иде: хәзерге шартларда хезмәткәрләрнең күп булуы кирәк. Казан мисалында карыйк: вакцина ясату пунктларына гына да ким дигәндә 28 табиб куярга кирәк», – диде министр урынбасары.

Вакцинаның чирдән тулысынча сакламавы турында без генә түгел, белгечләр дә күптәннән әйтеп килә. Әмма ул аяныч нәтиҗәләрдән саклый. Рәсми мәгълүматлардан күренгәнчә, вакцина ясату түбән дәрәҗәдә булган илләрдә үлүчеләр саны югары. Әлегә республика буенча прививка кадаткан кешеләр саны 1995481не тәшкил итә. Кабат вакцина ясатучылар саны 66 меңнән артык.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Фикер

Михаил ЛЮБИМОВ, журналист:

Джонатан Свифт: «Мышление никогда не излечит человека от неверного мнения, которое никогда не приобретается в результате мышления», – дигән. Ягъни антиваксерларның (вакцинациягә каршы кешеләр. – **Ред.**) аерым фикере – фикерләү процессы нәтиҗәсе түгел, ниндидер капма-каршы нәрсә ул. Бу – «ошый-ошамый» принцибы буенча барлыкка килгән, «прокат»ка гына алып торган фикер. Бернәрсә белмичә генә дөньяны аңлатып бирү өчен менә дигән мөмкинлек. Мондый фикер белән көрәшү мөмкин дә түгелдер. Әгәр кеше нинди дә булса фикер төзү өчен бернинди дә көч куймаган икән, аның ниндидер дәлил яисә мәгълүматка игътибар итүен көтү – ахмаклык. Малевичның «Кара квадрат» картинасы бар бит әле. Гадәттә, аңа ике төрле реакция күзәтелә. Бер кеше аны сәнгать үрнәге дип таный, әмма популярлыгын аңламый. Тик аңлыйсы һәм асылына төшенәсе килә. Бу – бер реакция. Икенче берәү: «Моны ничек сәнгать дип атарга була соң?» – дияр һәм үзенең хаклыгына чынлап ышаныр. Әнә шул икенче кешене антиваксер дип санарга була. Андый кеше теләсә нинди фәнни белемне инкарь итәчәк. Ул «Кара квадрат»ның асылы турында кызыксынмаячак, ни өчен аның сәнгать үрнәге булуын, аның кешелек тарихындагы әһәмиятен аңларга теләмәячәк.

QR-код: куллану инструкциясе

Татарстанның Сәламәтлек саклау министрлыгы республика QR-кодын алу тәртибе һәм аның гамәлдә булу вакыты турында аңлатты. Вакцина ясатырга ярамаган кешеләр QR-код алу өчен үзләре теркәлгән сырхауханәләргә мөрәҗәгать итәргә тиеш. Аны участок табибы рәсмиләштерә. Гамәлдә булу вакытын да ул билгели.

Ике компонентлы вакцинаның беренчесен яисә бер компонентлысын ясатканнар шулай ук теркәлү яисә яшәү урыны буенча сырхауханәләрдә электрон код алырга мөмкин. Аның гамәлдә булу вакыты – 24 көн. Бер генә дозасын ясаткан кешеләр белешмәне сырхауханәдә ала. Аның кулында вакцина ясату турында таныклык яки «Дәүләт хезмәтләре» порталында беренче уколны ясатуы турында мәгълүмат булырга тиеш.

Хәрбиләр дә сырхауханәгә мөрәҗәгать итә ала. Аларга хәрби билет күрсәтергә кирәк булачак. QR-код алты айга бирелә.

Сүз уңаеннан, коронавирус кичерү турында белешмә бер ел гамәлдә булачак. Бу хакта Россия сәламәтлек саклау министры Михаил Мурашко белдерде. Элегрәк аның вакыты алты ай иде.

Электрон таныклык гамәлдә

Татарстанда машина йөртүчеләргә ЮХИДИ хезмәткәрләренә автомобильнең теркәүгә алынуы турында электрон таныклык (QR-код) күрсәтү мөмкинлеге сынала. Электрон таныклыкны «Госуслуги. Авто» кушымтасы аша алырга мөмкин. Теркәлгәннән соң, сервис машина хуҗасы, таныклыкта күрсәтелгән мәгълүматлар (автомобиль номеры, маркасы, җитештерү елы һ.б.) турында автоинспекция базасыннан барлык мәгълүматларны күрсәтәчәк. Әмма, ведомствода билгеләп үтелгәнчә, автоинспектор кәгазь таныклыкны да таләп итә ала.

Кушымта ярдәмендә йөртүче үзенең машинасын башка кешегә дә тапшыра ала. Шулай ук Дәүләт автомобиль инспекциясенең транспорт чаралары реестрыннан машина тарихын карарга, автомобильне теркәүгә, «права»ны алыштыруга язылырга мөмкин.

Кыш бабай поезды килә

rzd.ru

15 декабрьдә Казанга Кыш бабай поезды килеп төшәчәк. Бу хакта «Россия тимер юллары» матбугат хезмәте хәбәр итә. Поезд 5 декабрьдә Великий Устюгтан кузгалып, 36 шәһәрдә тукталыш ясарга тиеш. Бу шәһәрләрдә балалар һәм әти-әниләр, бәйрәм чараларында катнашып, тылсымлы әкият герое аша котлау открыткалары юллаячак, Яңа ел бүләкләре алачак. Поезд килеп төшәргә 20 минут кала, вокзалда һәм вокзал яны мәйданчыгында бәйрәм башланачак. Вокзалга керү һәм чарада катнашу өчен QR-код күрсәтү яки ПЦР-тест узу (чара башланырга 72 сәгать кала) кирәк. Расписаниесенә караганда, Кыш бабай безгә 9 сәгать 25 минутта килеп төшәчәк, кичке җидедә китәчәк. Сүз уңаеннан, пандемия аркасында, узган ел поезд Казанга килмичә калган: Кыш бабай белән интернет аша гына матбугат конференциясе узган.

Яңалык

Декабрь ае үзгәрешләре

Россиядә социаль челтәрләрдән бушлай файдалану мөмкинлеге ачыла, табиблар хезмәтенә түләүгә реформа ясала, ял итү өчен илләр исемлеге киңәя. Декабрь ае безгә әнә шундый һәм күп кенә башка үзгәрешләр алып килә. Шуларның иң мөһимнәренә тукталып үтәбез.

Корпоратив «симка» эшләми

1 декабрьдән SIM-картаның тәгаен хуҗасы турында мәгълүматларны дәүләт мәгълүмат базасына кертүне таләп иткән закон үз көченә керә. Эш урыныннан бирелгән «симка» кулланучыларга телефоннарын сүндерү белән яный бу. Сәбәбе – күп кенә компанияләрнең, аеруча кече һәм урта бизнесның SIM-карта кулланучы турында мәгълүматны «Дәүләт хезмәтләре» порталының бердәм идентификация һәм аутентификация системасына (ЕСИА) кертергә ашкынып тормавы. Цифрлы үсеш министрлыгы мәгълүматлары буенча, бүгенгә Россия компанияләре 13,3 миллион хезмәткәрнең генә «симка»сын портал аша раслаган.

Мошенниклар сайтлары ябыла

Төрле юллар белән кешеләрдән акча каерып ятучыларның сайтларын судсыз гына, бик тиз ябып кую мөмкинлеге бирердәй закон үз көченә керә. Банкларның рәсми сайтларына охшатып эшләнеп, финанс пирамидаларына яки банкларның мәгълүмат системасына керүне тәкъдим итүче сайтлар турында сүз бара. Документта Үзәк банкка мондый ресурсларны тыелган мәгълүматлар исемлегенә кертү хокукы бирелгән. Сайтны ябу турында карарны, Үзәк банк башлыгы яки аның урынбасары мөрәҗәгате буенча, генераль прокурор яки аның урынбасары кабул итәчәк.

Бушлай интернет

Ай башыннан элемтә операторлары социаль әһәмиятле интернет-ресурслардан бушлай файдалану мөмкинлеге бирергә тиеш. «Элемтә турында»гы Законга бу җәһәттән тиешле үзгәрешләр кертелгән. Интернет-ресурслар исемлеге расланган да инде. Аңа «Дәүләт хезмәтләре» порталы, дәүләт, җирле үзидарә органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондлары сайтлары гына түгел, бәлки социаль челтәрләр, интернет-кибетләр, эзләү сервислары, яңалык агрегаторлары да (барлыгы – 371 ресурс) кергән.

Табиблар хезмәтенә түләүгә реформа

Россиянең 7 төбәге – Белгород, Курган, Омск, Оренбург, Тамбов өлкәләре, Якутия, Севастополь табибларга эш хакы түләүнең тармак системасын гамәлгә кертү буенча пилот проект башлап җибәрә. Реформаның максаты – табибларга, шәфкать туташларына бер генә смена эшләгәндә дә әйбәт хезмәт хакы түләү. Аларның хезмәт хакы окладтан һәм башка түләүләрдән торачак. Пилот проект нәтиҗәләре буенча табиблар хезмәтенә яңача түләү бөтен ил күләмендә гамәлгә кертеләчәк.

Прививкалы кешеләр сәяхәткә бара

1 декабрьдән Израиль «Спутник V» прививкасын ясаткан Россия туристларын үзенә кертә башлаячак. Безнең вакцинаны бу илдә 15 ноябрьдә таныганнар.

Сүзгә-сүз

Ибраһим ШӘЕХАБЗАЛОВ, Россия ислам институтының тәрбия эшләре буенча ректор урынбасары:

Минем күзәтүләремчә, Татарстаннан читтә үскән татарларда ватанпәрвәрлек хисе көчлерәк. Алар тел өйрәнүгә аңлы рәвештә якын килә. Аларга татар мәдәнияте белән бәйле һәр нәрсә кызык. Ә гомер буе безнең республикада яшәүчеләр яңа белемнәргә бик омтылмый.

(«Казанфест» басмасында чыккан әңгәмәсеннән)

ТАТАРСТАНДА – ИМИНИЯТЛӘШТЕРУ

2021 елның 6 аенда республикада яшәүчеләр 7,8 млрд сум күләмендә иминият түләве алган. Узган елның шул ук чорыннан 36,5 процентка күбрәк бу. Әлеге сумманың 2,6 млрд сумы ОСАГО полислары буенча түләнгән. Анысы узган елгыдан 600 млн сумга күбрәк.

ИМИНИЯТЛӘШТЕРУ ОЕШМАЛАРЫ ХАЛЫКТАН ҖЫЙГАН АКЧА КҮЛӘМЕ	16,1 млрд сум ↑ 8,6 процентка күбрәк
САТЫП АЛЫНГАН ПОЛИС САНЫ	1,8 млн сум ↑ 6,8 процентка күбрәк

Алимент түләмәгән өчен – төрмәгә

Әгерҗе районында алимент түләмәгән 46 яшьлек ир төрмәдә утырачак. Суд аны балаларына 390 мең сум күләмендә бурычын түләмәүдә гаепле дип таныган. Бу хакта Татарстан прокуратурасының матбугат хезмәте хәбәр итә.

Ул 2019 елның августыннан берсеннән-берсе кечкенә өч баласына ай саен алимент түләргә тиеш булган. Әмма үзенең бурычын үтәмәгән. Шулай итеп, алимент буенча 390 мең сумнан артык бурычы җыелган. Ул моңа кадәр дә административ, җинаять җаваплылыгына тартылган булган. Ир үзенең гаебен тулысынча таныган. Суд аны 6 айга ирегеннән мәхрүм иткән.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Каһәрле тел: еласаң ела, көлсәң көл

Моңарчы андый интервью караганым юк иде әле. Дөресрәге, дәүләт лидеры журналистка биргән андый интервьюны. Чал чәчле тыныч журналист һәм әледән-әле чыгырыннан чыгучы Президент. Четерекле булсалар да, ипле генә итеп бирелгән сораулар һәм ачудан янган күзләр, усал йөз, дәүләт җитәкчесе беркайчан да әйтергә тиеш булмаган кискен, куркыныч кәлимәләр.

Сүзем Белоруссия Президенты Александр Лукашенконың BBC журналисты Стивен Розенберг белән әңгәмәсе хакында иде. Аңа сәбәп – Белоруссия белән Польша чигендә Белоруссия яклап җыелган 7000нән артык мигрант һәм качаклар. Чик буендагы чуалышлар кыйтгада Макрон белән Меркель, башка илбашлары килеп кысылырлык гаугa, резонанс тудырмаса, интервью, ихтимал, булмас та иде. Хәер, әңгәмә ул вакыйгага гына кайтып калмады. Ул Европа уртасына урнашкан илдәге вазгыятьне ачыклады, ил лидерының ярымтоннарны кабул итмәгән, ак һәм карадан гына торган карашларын, холкын янә бер кат дөньяга ачты.

Әңгәмә ил башкаласы Минскидагы узган елгы күләмле урам протестларына, аларның сәбәпләренә кереп китүгә үк, Президент авызыннан чиркангыч сүзләр яңгырады: «Сез финанслаган ул адәм актыкларының барысын да суеп чыгачакбыз!» (Мы вырежем всех мерзавцев, которых вы финансировали»). «Җавапка тартабыз» түгел, башкача. Илбашы әйтә торган сүзме бу? Моны әйтер өчен тәрбиясезлектән дә бигрәк, явыз, хәтта ки кансыз кеше булу кирәктер. Аның мантыйгы буенча режимга каршы булган, үткән җәйне Минск урамнарын тутырган һәр белорус – сатлыкҗан һәм Көнбатыш агенты. Җәй, көз буе барган протестлар – Көнбатыш этлеге.

«Европа берлегенә мин төкерәм! Алар мине инде чирек гасыр буе легитим санамый». Монысы – интервьюда мине сискәндергән икенче җөмлә. Европа берлегендә 27 ил. Интервью алучы ватаны Бөекбритания – берлектән чыккан бердәнбер дәүләт булса да, шул 27 ил белән бер икътисади һәм сәяси кырда гомер итүче, бер хәрби союзда торучы мәмләкәт. Лукашенко 500 миллионга якын халык яшәгән, тулай эчке продукты Белоруссиянекеннән 300 тапкыр зуррак, уртача хезмәт хакы 2000–2500 евро (Белоруссиядә ул тулыр-тулмас 400 евро) булган 28 ил өстенә, алар фикеренә биек манарадан төкерә булып чыга. Акыллы кеше сүзләреме бу? Юк! Бу – истерика…

Лукашенко, әйтергә кирәк, 1990 нчы еллар продукты, нәкъ шул елларда калыккан сәясәтче. Буталчык, болгавыр елларда хакимияткә очраклы көчләр, очраклы кешеләр еш килә, сәнәктән көрәк булганнар күбәя. Халык андый чорларда, күрәсең, салкын акылдан бигрәк, күбрәк хис, эмоцияләр белән сайлый, ялган вәгъдәләргә ныграк ышана. Төрле популистлар, Жириновский кебек сәяси клоуннар (сүз уңаеннан, туксанынчы еллар азагында аның безнең бүгенге герой – Лукашенконы «конюх» дип атаганы истә), икешәр тапкыр утырып чыккан Януковичлар күбек булып күтәрелә, өскә калкып чыга. Колхоз рәисе урынбасары, аннары совхоз директоры булып эшләгән Лукашенконың шул шаулы елларда Белоруссия парламентына эләгүен, анда коррупция белән көрәш бүлеген җитәкләвен кайберәүләр әле хәтерлидер. Сүз эзләп кесәгә кермәгән аграрийның парламентта ярыйсы күләмдә сәяси очколар туплый алуын һәм әлеге дә баягы шул популизм ярдәмендә 1994 елда президент тикле президент булып китүен дә.

Һәм менә 27 ел ярым буе ул – илнең иң югары кәнәфиендә. Кайбер монархларны исәпләмәгәндә, бөтен Евразия континентында да ул кадәр вакыт югары пост биләгәннәр юк. Кайсы яктан гына карама, бу – узурпация. Әлеге кешегә «Европаның соңгы диктаторы» дигән исем тагылуга да ике дистә еллап булыр. Ә ничек такмаска? Оппозиция ул килгәннән бирле идән астында. Юкка чыккан сәясәтчеләр, журналистлар, аның белән килешмәгән бизнесменнар. 27 ел эчендә хәбәрсез югалучылар саны, 2020 елгы протест акцияләрендә катнашканнарны да кертеп, йөздән артып китә, диләр. Шул хәлләр өстенә берниндн кысага да сыймаган белдерүләр, тик тора белмәгән акылсыз тел.

«Мин үз дәүләтемне тәрәккыятле (цивилизацияле) дөнья артыннан алып барырга җыенмыйм». Демократик Европага терәлеп үк торган дәүләт җитәкчесе үткән гасыр азагында ук әйткән, хәтергә шул чорда ук уелып калган сүзләр. Кая алып бара соң ул Белоруссияне? Төньяк Корея, Венесуэла тарафынамы? Әллә ул үз илен элек үзе җитәкләгән колхоздан артык күрмиме? Кеше аңы һәм холкының төбендә ятканны алып ташлап булмаганны аңлаткан әйтем бар. Лукашенко очрагында ул «Кешене колхоздан тартып чыгарып була, ә колхозны кешедән чыгару мөмкин түгел» рәвешендә яңгырамый микән? Колхоз рәисләренең, мәгълүм ки, төрлесе булды. Араларында дуамал, чит фикерне дөрес булса да кабул итә белмәгән үзсүзле затлар, колхозчыны дер калтыраткан тираннар да юк түгел иде. Тик 10 миллионлы олы ил ул – ил, өч бригададан торган колхоз түгел.

Интервьюга әйләнеп кайтыйк. Һәрбер әйткәненә «ярар» дип торганга күнеккән, төртмәле сораулардан ярсыган җитәкче бераздан «сез»дән «син»гә күчте. Журналист: «Владимир Путин сезгә, оппозиция белән эшләргә өйрәнергә кирәк, дигән киңәш әйткән иде кебек», – диюгә, Лукашенко тагын чәчрәп чыкты һәм әллә гомумән дә уйламыйча, әллә Россия Президентына төрттерәсе килеп: «Путин кайчан Навальный белән бер өстәл янына утыра, мин дә шул чакта Тихановская белән сөйләшүләр башлаячакмын», – диде.

Төп оппозиционерларның берсе булган Светлана Тихановскаяны искә алгач, аның бу чәршәмбедәге Европарламенттагы чыгышын, Европа берлеге керткән чикләү-санкцияләрдән тулысынча канәгать булмавын әйтеп үтү дә урынлыдыр. Ул Европа лидерларын кыюрак булырга чакырды һәм: «Белоруссиядә сәяси тоткыннар саны биредә утырган депутатлар санынннан күбрәк», – дип белдерде. Исебезгә төшерик: Европарламентта 705 депутат исәпләнсә, ул төрмәгә тыккан сәяси тоткыннар саны, язуларынча, 800 тирәсе. Лукашенко белән очрашкан BBC журналисты 873 санын атады. Тик үз репертуарына тугры Президент монда да югалып калмады: «Бездә сәяси тоткыннар юк, сез котыртып закон бозган җинаятьчеләр генә бар», – дип белдерде…

КЕСӘДӘ – КОД, УЙДА – БӘЙРӘМ

elabuga.bezformata.com

Яшәеш

Халык яңа елдан могҗиза көтә. Һәр кешедә бер теләк – вирус бетсен иде. «ВТ» республика халкының кәефен белеште.

Азнакайда яшәүче Нәсимә Камалиеваның күңеле тыныч. Ире дә, үзе дә коронавируска каршы вакцина ясатып кайтка280ннар. Нәсимә апа урамга чыгарга, кибетләрдә йөрергә куркып тормый.

– Кесәдә – код, уйда – бәйрәм. Карлар яву белән, күңелгә рәхәтлек өстәлде. Безнең якларда башка җирдәге төсле декабрь уртасы җиткәнне көтмиләр, чыршыларны ноябрь ахырында ук бизәп куялар. Азнакай урамнарыннан кайтып керәсе килми. Бөтен җирдә – бәйрәм рухы. Сөембикә урамын кышкы чорга ябып торып, балалар өчен тау ясыйлар. Бөтен җир җемелди, матурлыкны күреп, баштагы начар уйлар тарала, – ди ул. – Авылларда да шул ук хәл. Әниемнең авылы Әлкәйгә кайтып йөрибез. Шунда яшәүче бер кеше ел саен урамда чыршы бизи. Аның матурлыклары! Шөкер, кешеләр моңаеп утырмый. Үз күңелен үзе күреп яши белә.

Нәсимә апалар ел саен чыршы да бизәп куялар икән. 1 нче сыйныфта укучы оныкларын шулай сөендерәләр.

Чыршы бизәү дигәннән, Мөслим районының Күбәк авылында гомер итүче Камаловларга бу эштә тиңнәр юк. Алар, тәрбиягә алган сабыйларының күңелен күрик дип, ел саен өйләрен бизиләр. Ул гынамы, урамнарына боздан төрле сыннар ясап куялар. Зур чыршы да бизәлә.

– Карны кадерләп җыеп кына торабыз. Күршеләр дә карын әрәм итми, кертеп бирәләр. Сыннарны әкренләп ясый башларга иде инде исәп. Җәнлекләрне дә күп итәм, Кыш бабай белән Кар кызы сыны да ясармын дип хыялланам. Өйне бизәр өчен гирляндаларның яңаларын алдык. Бик матур булыр дип торабыз, – ди Ирек Камалов.

Чаллыда яшәүче Алчәчәк Шәвәлиева: «Әле Яңа ел бәйрәме хакында уйлаган да юк, көнебез мәшәкатьләр белән уза да китә», – ди.

– Өйдә кечкенә балалар булгач, чыршы бизәмичә дә булмый. Утлар элдек инде. Тик менә каядыр барып ял итү хакында уйлаган юк. Гадәттә без бәйрәмгә авылга кайтабыз, – ди ул.

Казанда яшәүче Лилия Галиәхмәтованың Яңа ел бәйрәменә бөтенләй исе китми.

– Ниндидер могҗиза көтеп утырмыйбыз. Әле чыршы да бизәмәдек. Безнең өчен бу бәйрәм гадәти бер көн кебек. Ел саен гаиләбез белән бергә булабыз. Без үзебез дә бишәү инде. Иремнең әнисе исә бөтенләй башкача уйлый. Ул һәрчак Яңа ел төнендә өстәлләр әзерләп, безне кунак итә, – ди Лилия.

Алабугада яшәүче Адилә Шәехова бер оешмада хисапчы булып эшли. Алар инде бөтен эшнең хәстәрен алдан күргән.

– Ноябрь уртасында ук бер кафены белешеп куйдык. Анда QR-кодлар белән кертәләр. Прививка ясатмаганнар, бәйрәмгә эләкмәячәкләрен белгәч, хастаханәгә барып ясатып кайтты. Бөтенебез дә барырга дип планлаштырып торабыз. Вирусның очы-кырые күренми. Аның беткәнен көтеп утырып булмый. Матур итеп яшәргә, һәр көннең кадерен белергә кирәк, – ди ул.

Кукмара районында урнашкан «Туган як» кафесы хуҗасы Минзилә Фәрхетдинова быел корпоративларга килгән һәр кешедән QR-код сорала һәм тән температурасы үлчәнеп кертелә, дип искәртә.

– Халык бәйрәмгә сусаган. Кафега килеп күңел ачарга теләүчеләр бар. Башка елларда дүртәр көн рәттән бәйрәм ясый идек. Быел ике көнгә кешеләр җыелды инде. Әгәр тагын теләк белдерүчеләр булса, тагын бер көн ясыйбыз. Белеп булмый, әле бит бәйрәмгә кадәр бер айлап вакыт бар, – ди ул. – Бездәге корпоративларны бик яраталар. Күрше районнардан да килеп күңел ачалар. Ел саен төрле җырчылар чакырабыз. Бәйрәмне кызым Марсилә белән киявем Илфир алып бара. Килгән кеше рәхмәт әйтеп китә. Иң мөһиме – авырмыйк. Шулай булганда гына күңелләр күтәрелә, бәйрәмнәр уздырасы килә.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ӘНИЛӘР КӨНЕ БЕЛӘН!

20 елдан артык ноябрьнең соңгы якшәмбесендә Россиядә Әниләр көне билгеләп үтелә. Шул уңайдан Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова редакциябез аша әлеге бәйрәм белән котлау сүзләрен җиткерә.

«Бу – хатын-кызның мактаулы хезмәтен, ана булу һәм бала тәрбияләү бәхетен данлаучы бәйрәм. Баланың рухи-әхлакый һәм интеллектуаль тәрбиясендә әниләрнең роле бик зур. Нәкъ менә шуңа күрә безнең илдә гаилә мәсьәләләренә игътибар елдан-ел арта, ә аналарга һәм балаларга ярдәм итү дәүләт социаль сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренең берсе булып тора», – диелә министр котлавында.

Эльмира Зарипова әйтүенчә, федераль дәрәҗәдә күрсәтелгән ярдәмнән тыш, Татарстанда да өстәмә чаралар каралган. Президент Рөстәм Миңнехановтәкъдиме буенча кертелгән өстәмә социаль ярдәм чараларының максаты – гаиләләрнең иминлеген, аларның тормыш сыйфатын арттыру.

«Балаларга бүләк иткән җылыгыз һәм назыгыз аларга илебезнең лаеклы гражданнары, сезнең таянычыгыз һәм ярдәмчеләрегез булырга ярдәм итсен. Үз балаларын гына түгел, тәрбиягә алган, сәламәтлекләре ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларны тәрбияләүче хатын-кызлар аерым рәхмәткә лаек. Бәйрәм көнендә барыгызга да сәламәтлек һәм иминлек телим. Һәр гаиләдә мәхәббәт, бер-береңә хөрмәт, җылылык һәм иминлек хөкем сөрсен!» – диелә министр котлавында.

Авыру капитализм

ТР Дәүләт Советында

Бу сүзләрне матбугат конференциясендә Дәүсоветтагы КПРФ фракциясе җитәкчесе Хафиз Миргалимов әйтте. Коммунист депутатларның җәмгыятьне бүгенге рәвешендә кабул итә алмаулары аңлашыла. Әмма шул ук вакытта бүгенге шактый ук тотрыксыз тормыштан зарланучылар алардан башка да очрый. Яңа проблемаларның әледән-әле туа торуын җитәкчелек тә таный һәм авырлыктан чыгу юлларын эзли.

Менә без дә республика бюджетын кабул иткәндә җитәкчеләр авызыннан «заманалар бик гади түгел», «бюджет киеренке шартларда кабул ителә…» кебек сүзләрне еш ишетәбез. Иҗтимагый формация үзгәргәндә бер кайгысыз гына яшәп булмавы аяз көндәге күк йөзе кебек ачык инде ул. Шулай да Татарстан илнең үсешкә юл тоткан төбәкләреннән санала.

Әлбәттә, Хафиз иптәш әйтмешли, акча беркайчан да җитми инде ул, әмма кайбер тармакларга акча тиешенчә бирепбетерелми. Бездә фән өлкәсе бигрәк тә мескен хәлдә. Депутат Фәтбир Сафин әйтүенчә, СССР вакытында фән үсеше өчен бюджет акчасының 8 проценты чамасы бирелгән, ә хәзер 1 проценты гына. Депутат, әлбәттә, ил күләмендә фикер йөртә иде. Фәтбир Сафин Россиядә тулай продукция җитештерүнең төрле елларда ничек булуын анализлаган. Аның әйтүенчә, дөньяның күп илләре ышанычлы адымнар белән алга атлаганда, бүген тулай продукция җитештерү күләме буенча Россия 65 нче урынга тәгәрәгән. Без Малайзиядән дә артта икәнбез. Илнең төп акча документын да ул «стагнация», ягъни торгынлык бюджеты дип атады.

Депутатларның һәр сүзенә аңлатма бирергә җыенмыйбыз, әмма зур тизлек белән үсешкә барабыз дип, иң югары дәрәҗәдәге җитәкчеләребезнең дә горурланып сөйләгәне юк, ә менә «Россиянең төп дошманы – хәерчелек» дигән сүзләрне ишеткән бар. Иле нинди – төбәкләр дә шундый инде ул, без бер җепкә бергә теркәлгән. Бердәнбер юаныч – Татарстанның алдынгылар рәтендә булуы. Һәм КПРФ әгъзалары, үзләре оппозициядә булсалар да, Татарстан җитәкчелегенең зур эшләр башкарырлык көчле команда икәнен таныйлар. Хафиз иптәш бу турыда турыдан-туры әйтте һәм: «Әгәр гавами хакимият оештыру принциплары турында федераль закон берниндн үзгәрешсез кабул ителсә, мондый команда таркалырга мөмкин, ә моннан илгә файда булырмы?» – диде.

Алдан тәгаенләгәнчә, КПРФ әгъзалары республика бюджеты турында гына сөйләргә тиешләр иде. Дөрес, бу хакта сүз булды. Фракциягә халыктан барлыгы 70 тәкъдим кергән, шуларның 21е профильле комитетка һәм Финанс министрлыгына җибәрелгән. Хафиз Миргалимов әйтүенчә, КПРФ фракциясе тәкъдимнәре бюджет проектын язганда исәпкә алынган.

Киләсе елга СССР төзелүгә 100 ел тулачак. Бу юбилей ил күләмендә ничек бәйрәм ителер – әйтү кыен, шулай да КПРФ моңа әзерләнә башлаган инде. Аларның чыгышларында совет чорын сагыну, үткәннең иң яхшы якларын бүгенге тормышыбызга күчерү кирәклеге турындагы сүзләрне күп ишетербез әле. Алар халык авыру капитализмда яшәргә тиеш түгел дип бара.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

«ҮЗӘК» БУЛМАГАНГА ҮЗӘК ӨЗЕЛӘ

АЛДЫНГЫ ТӘҖРИБӘ НИГӘ АЗ КУЛЛАНЫЛА?

Республика хуҗалыклары 2010 елгы корылык нәтиҗәсендә 6 миллиард сумнан артык керемен югалткан иде. Кызганыч, зыян күләме быел да шактый булыр. Татарстан Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров сүзләренә караганда, әйтик, сөт җитештерүдән планлаштырылган керем күләме 2 миллиард 300 миллион сумга кимрәк булачак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Югалтуларның сәбәпчесе бер корылык кына түгел, билгеле. Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, ягулык-майлау материаллары, электр энергиясе, ашламалар, запас частьлар һәм башка кирәк-яракларга бәя һаман да өскә үрмәли. Җитештерелгән продукциянең үзкыйммәте ни өчен айлап түгел, көнләп артуга гаҗәпләнәсе дә юк. Әйтик, хуҗалыкларның көндәлек керем чыганагы булган сөтнең үзкыйммәте узган елның шул чоры белән чагыштырганда 18 процентка арткан. Ит, ашлык, яшелчә, җиләк-җимеш һәм башка продукцияләр буенча да хәлләр шул чама.

Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Ленар Гарипов әйтүенчә, җитештерелгән продукциянең үзкыйммәте арта бару нәтиҗәсендә, 2021 елда хуҗалыкларның акча кереме 4 миллиард 100 миллион сумга түбән тәгәрәгән.

– Авыл хуҗалыгында эшләүчеләр кыенлыклар алдында беркайчан куркып калмады. Хәзер дә шулай. Сөт җитештерү күләменең узган ел белән чагыштырганда 15 мең тоннага күбрәк булуы да шуны раслый. Ел ахырына кадәр җитештерелгән сөт 1 миллион 950 мең тоннага җитәр дип өметләнәбез, – ди Ленар Гарипов.

Терлекчелек тармагында төрле хуҗалыкларның күрсәткечләре дә нык аерыла. Берәүләр дөньяның иң алга киткән илләреннән уздырып эшләсә, икенчеләрдә савым күләме кәҗәнекеннән дә кимрәк. Андыйлар ни өчендер үзебездә булган уңай тәҗрибәне кулланырга теләми.

Югыйсә Татарстанның терлекчелек тармагында Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан хупланган алдынгы тәҗрибә дә шактый. Терлекчелектә иң югары нәтиҗәләр белән эшләүче Кукмара, Саба, Балтач, Мамадыш, Арча, Әтнә һәм кайбер башка район хуҗалыкларында нәкъ менә шуннан файдаланалар. Биредә сүз терлекчелектә азык үзәкләре булдыру турында бара.

Сыерның сөте – телендә, дип тикмәгә генә әйтелмидер. Кукмара районы Вахитов хуҗалыгындагы терлек азыгы үзәгендә булганда, моның шулай икәнлегенә тагын бер кат инандым. Сыйфатлы һәм балансы азык куллана башлагач, биредә савым күләме бермә-бер арткан. Азык үзәге эшли башлаганнан бирле, хуҗалык ай саен 4 миллион сум өстәмә керем ала.

Терлекчелектә әйдәп баручы һәр район, һәр хуҗалыкта азык үзәкләреннән файдаланалар.

Яңалыкның тагын бер уңай ягын әйтми үтә алмыйм. Балансы азык үзәкләре якындагы шәхси һәм фермер хуҗалыкларын да терлек азыгы белән тәэмин итә башлаган. Күпләп мал-туар асраучылар әйтүенчә, махсус программа нигезендә берничә дистә төр файдалы кушылмалар белән әзерләнгән мондый азыкның бәясе дә арзанрак, сөтне дә күбрәк җитештерергә мөмкинлек бирә. Авыл тирәләрендә көтүлекләр генә түгел, печәнле болыннар бетеп барганда, монысы мал асраучылар өчен аеруча мөһим.

Балтач районы «Татарстан» хуҗалыгы мисалыннан күренгәнчә, азык үзәге булдыруга киткән чыгымнар озак еллар дәвамында түгел, ә санаулы айлар эчендә үзен аклый. Хуҗалык белгечләре әйтүенчә, бина төзү һәм 2 стационар азык үзәгенә кирәкле җайланмалар сатып алуга киткән 64 миллион сум акча чыгымы үзен 23 айда тулысынча аклаган.

Яңарак кына Нурлат районы «Южный» агрофирмасында балансы азык үзәгендә булган идем. Әллә ни зур булмаган оешма берничә айдан 9 мең баш терлеккә җитәрлек югары сыйфатлы һәм балансы азык әзерли башлаган.

Хуҗалык белгече Наталья Козина әйтүенчә, тәүлегенә 350 тонна сыйфатлы азык әзерли алучы мондый үзәк якын киләчәктә тирә-як хуҗалыкларга, шул исәптән фермер һәм шәхси хуҗалыкларга да хезмәт күрсәтә алачак.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов еллык Юлламасында балансы һәм югары сыйфатлы азык үзәкләрен һәр районда булдыруны максат итеп куйган иде. Шактый вакыт узса да, мондый үзәкләр әлегә нибары 12 районда гына ачылган. Калганнар исә искечә эшләүләрен дәвам иттерә.

Берүзе Балык Бистәсе, Түбән Кама, Яңа Чишмә һәм Чүпрәле районнары кадәр сөт җитештерүче Әтнә терлекчеләренең тәҗрибәсе дә шуны раслый. Югыйсә әлеге район хуҗалыкларында савым сыерлары саны да ике тапкыр артык. Тик нәтиҗә генә аксый…

Камил СӘГЪДӘТШИН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме җиденче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы егерме җиденче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 238-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
3. «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 237-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
4. Зеленодольск шәһәренә Россия Федерациясенең «Хезмәт батырлыгы шәһәре» мактаулы исемен бирү турында Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы үтенечнамәсе хакында.
5. «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 17357-8 номерлы федераль закон проекты турында (яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау максатларында кайбер чикләү чараларын кертү өлешендә).
6. «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 1256381-7 номерлы федераль закон проектына төзәтмәләр хакында.
7. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 206-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
8. «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 231-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
9. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 239-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
10. «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез милекнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 245-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
11. «Татарстан Республикасында умартачылыкны үстерү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 236-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
12. «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 246-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
13. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 248-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
14. 2022 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы проекты турында.
15. Профессиональ даими нигездә эшләү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатын сайлау турында.
16. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты составындагы үзгәрешләр турында.
17. 2020 елда Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү программаларын гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты доклады.
18. Татарстан таможнясы эшчәнлеге турында мәгълүмат.
19. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына экскурсоводлар (гидлар), гид-тәрҗемәчеләр һәм озатып йөрүче инструкторлар эшчәнлеген хокукый җайга салу өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 1212915-7 номерлы федераль закон проекты турында.
20. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1245543-7 номерлы федераль закон проекты турында (җитештерү һәм куллану калдыклары белән территорияләрне пычратуга бәйле хокук бозулар өчен административ җаваплылыкны арттыру хакында).
21. «Ау турында һәм аучылык ресурсларын саклап калу хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 10309-8 номерлы федераль закон проекты хакында (аучылык минимумы таләбен өйрәнү бурычын беркетү максатларында).
22. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 8.32 статьясына үзгәреш кертү хакында» 9732-8 номерлы федераль закон проекты турында (урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылыкны һәм җинаять җаваплылыгын аерып карау өлешендә).
23. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Федераль законның 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» 9761-8 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе Хөкүмәтенә янгынга каршы федераль хезмәтнең территориаль бүлекчәләре урнашкан торак пунктлар исемлеген раслау вәкаләтләрен бирү өлешендә).
24. «Россия Федерациясе гражданнарының Россия Федерациясе чикләре эчендә иркен күчеп йөрү, яшәү һәм тору урынын сайлау хокукы турында» Федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 1249322-7 номерлы федераль закон проекты турында (гражданның тиешле теркәве булмаган очракта «тору урыны» төшенчәсен төгәлләштерү турында һәм күрсәтелгән урынны мондый очрак өчен төрле юридик фактлар нигезендә суд тәртибендә билгеләү мөмкинлеге хакында).
25. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 543-8 номерлы федераль закон проекты турында (гарантияле тәэмин итүчеләр һәм челтәр оешмалары тарафыннан электр энергиясен исәпкә алу приборларын урнаштыруны башкару йөкләмәләрен үтәмәгән өчен административ җаваплылыкны төгәлләштерү өлешендә).
26. «Ветераннар турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 3060-8 номерлы федераль закон проекты турында (Чечен Республикасында һәм коралны конфликт зонасына кертелгән аңа чиктәш Россия Федерациясе территорияләрендә коралны конфликт шартларында һәм Төньяк Кавказ регионы территориясендә контртеррористик операцияләр барышында хезмәт вазыйфаларын башкарган Россия Федерациясе прокуратура органнары прокурорларына һәм тикшерүчеләренә, Россия Федерациясе Тикшерү комитеты хезмәткәрләренә хәрби хәрәкәтләр ветераны статусын бирү һәм тиешле социаль ярдәм чараларын билгеләү хакында).
27. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 71 статьясына үзгәреш кертү хакында» 5463-8 номерлы федераль закон проекты турында (хәрби хәрәкәтләр барышында һәлак булган яисә имгәнүләрдән үлгән хәрби хәрәкәтләр ветераннарының балаларына билгеләнгән квота чикләрендә югары уку йортларына укырга кабул ителү хокукы бирү өлешендә).
28. «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 50 һәм 56 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 11602-8 номерлы федераль закон проекты хакында (тәмәке продукциясенә акцизлардан салым керемнәрен 50 процент норматив буенча Россия Федерациясе субъектлары бюджетына кертү өлешендә).
29. «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» Федераль законның 26 һәм 38 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ярославль өлкә Думасы закон чыгару инициативасы турында.
30. «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 13 статьясына һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 10375-8 номерлы федераль закон проекты хакында (хайваннар дөньясы объектларыннан файдаланган өчен җыем түләтүнең аерым мәсьәләләре өлешендә).
31. «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 84 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 15841-8 номерлы федераль закон проекты хакында (физик затларны салым органнарында исәпкә кую тәртибен камилләштерү өлешендә).
32. «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 9703-8 номерлы федераль закон проекты турында (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуларда потенциаль катнашуы максатларында аларны үстерү программаларын гамәлгә ашыруны тәэмин итүдә заказчыларның хокукларын билгеләү өлешендә).
33. «Россия Федерациясендә сәүдә-сәнәгать палаталары турында» Россия Федерациясе Законының 15 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 6598-8 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе Сәүдә-сәнәгать палатасына шартнамәләрдәге каршы торып булмый торган хәлләрне таныклау тәртибен тәэмин итү вәкаләтләрен бирү хакында).
34. «Конкуренцияне яклау турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» Федераль законның 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 9719-8 номерлы федераль закон проекты турында (хуҗалык итүче субъектлар эшләгән акчаларның чик күрсәткечләрен монополиягә каршы контрольне кимәтү максатларында арттыру өлешендә).
35. Хөкүмәт сәгате: «Татарстан Республикасында халык сәнгать һөнәрләрен саклап калу, өйрәнү һәм үстерү турында».
36. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе
Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2021 елның 25 ноябре. № 1195-VI ДС

Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары итеп өч елга түбәндәгеләрне сайларга:

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә суд районы буенча:
1 нче суд участогына – Камалиев Илнар Фәнис улын;

Татарстан Республикасы Тукай суд районы буенча:
1 нче суд участогына – Дилмиева Айгөл Азат кызын.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе
Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2021 елның 25 ноябре. № 1196-VI ДС

КОТЛЫЙБЫЗ!

Урман хуҗалыгы өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Арча урман хуҗалыгы» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе – урманчы **Хәйруллин** Шамил Мәхмүт улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган урманчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге Вәкаләтле вәкиле эшләр идарәчесе **Әмирханов** Рөстәм Рифкать улы **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Дуслык ордены** белән бүләкләнде.

***

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Секретариаты җитәкчесе **Хәсәнов** Марат Сабир улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре буенча департаменты җитәкчесе урынбасары **Мөхәрләмов** Руслан Роберт улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Нефть һәм газ сәнәгате өлкәсендәге казанышлары, күп еллар буе намус белән эшләүләре өчен: В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең Скважиналарның җир астындагы өлешен ремонтлау идарәсе Әлмәт скважиналарның җир астындагы өлешен ремонтлау цехы операторы **Әһлиуллин** Рамил Тәлгать улына; В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур подразделениесе «Елховнефть» нефть-газ чыгару идарәсе җир асты катламнарындагы басымны тоту буенча операторы **Дылевский** Михаил Николаевичка; В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефтегазпереработка» идарәсе электр җиһазларын ремонтлау һәм карап тоту буенча электромонтеры **Хәертдинов** Әхәт Гамбәр улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Россия Саклык банкы» гавами акционерлык җәмгыятенең 8610 номерлы «Татарстан банкы» бүлекчәсе хезмәткәрләре: «Безналичные решения» идарә итүгә сервис хезмәте күрсәтү бүлеге башлыгы **Зәйнуллин** Роман Марат улына; 8610/0743 номерлы өстәмә офис җитәкчесе **Ильясова** Ләйсән Марс кызына; кече бизнеска сату идарәсенең 3 номерлы кече бизнес клиентларына сатуны оештыру бүлеге 8610/14 кече бизнес клиентларына сату белгечләре төркеменең кече бизнес клиентлары белән эшләү буенча әйдәүче менеджеры **Талипова** Энҗе Вәлияр кызына; «Электрощит» гавами булмаган акционерлык җәмгыяте коллективына, «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе директоры урынбасары **Бәдретдинов** Динар Альберт улына; Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы **Гаптрахимов** Ильяс Габделхәй улына; Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Алабуга районы һәм Алабуга шәһәре территориаль бүлекчәсе бюджетларны үтәү бүлеге консультанты **Касатов** Владимир Васильевичка; «Татарстан Республикасының Хоккей федерациясе» иҗтимагый оешмасы хезмәткәрләре: укыту-спорт эше белгече **Дюмин** Александр Сергеевичка; директор урынбасары **Закамский** Сергей Анатольевичка; директорның ярышлар уздыру һәм судьялар эшчәнлеген оештыру буенча ярдәмчесе **Суслов** Владимир Ивановичка; бухгалтер **Шәрифуллина** Венера Фәйзрахман кызына; Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Шурабаш төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең мари теле һәм әдәбияты укытучысы **Антипова** Олеся Игоревнага; «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясы каршындагы Татарстан халыклары яшьләр ассамблеясы» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы рәисе урынбасары **Камолов** Амриддин Бахридин улына; Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе мәгълүматлаштыру һәм мәгълүмат куркынычсызлыгын тәэмин итү бүлеге башлыгы, эчке хезмәт өлкән лейтенанты **Заһидуллин** Сергей Харис улына; Татарстан Республикасының «Арча урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесенең Сорнар участок урманчылыгы участок урманчысы **Николаев** Юрий Ильичка; «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Төбәк автоматлаштырылган мәгълүмат-идарәче системасы дирекциясе» дәүләт бюджет учреждениесе директоры **Садыйков** Айрат Халит улына; «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Халыкара мөнәсәбәтләр институты Тарих фәннәре һәм бөтендөнья мәдәни мирасы югары мәктәбенең антропология һәм этнография кафедрасы доценты **Фролова** Елена Валерьевнага; «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесенең Казан шәһәрендәге территориаль идарәсе профилактика бүлеге башлыгы **Ананьичева** Любовь Тимофеевнага; Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе башлыгы урынбасары – идарә бүлеге башлыгы (юл-патруль хезмәте һәм хокук саклау органнары белән хезмәттәшлек бүлеге), полиция полковнигы **Разумнов** Александр Викторовичка; Татарстан Республикасы Югары Суды судьясы **Гыйльманов** Әлфис Салихҗан улына; Татарстан Республикасы Югары Суды бүлеге башлыгы **Хәсәнова** Эльмира Рәшит кызына, «СтройДорТехнология» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең инженерлык геодезиясе хезмәте башлыгы **Максимов** Виталий Сергеевичка; «СтройДорТехнология» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең төзү эшләре өлкән җитәкчесе **Плюснин** Павел Андреевичка; «Строй-Инжиниринг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җитештерү лабораториясе башлыгы **Фәйзиев** Рифат Илшат улына; «СтройДорТехнология» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең төзелеш һәм монтажлау эшләре мастеры **Фәттахов** Руслан Рафаил улына; Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Ык буе территориаль идарәсе башлыгы **Мөстәкыймов** Хәлил Салих улына; Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең кадрлар эше буенча консультанты **Сөнгатова** Наилә Галимҗан кызына; Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының хезмәтне саклау һәм экологик куркынычсызлык секторы әйдәүче киңәшчесе **Черкасова** Светлана Геннадьевнага; «Алабуга-Волокно» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте хезмәткәрләре: инженер-химик **Герасимова** Анастасия Игоревнага, полимерлаштыру цехы башлыгы **Садриев** Руслан Зөлфәт улына; энергия белән тәэмин итү участогы башлыгы **Светчиков** Евгений Александровичка; «Татарстан Республикасы Композиторлар берлеге» төбәк иҗтимагый оешмасы әгъзасы **Фәйзулаева** Маргарита Павловнага; Татарстан Республикасы Питрәч районының ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасы рәисе **Фәйзуллина** Илгизә Мөхәммәд кызына **Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте** белдерелде.

***

Республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе, актив иҗтимагый һәм хәйриячелек эшчәнлеге өчен «Азык-төлек программасы агросәнәгать компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Мотыйгуллин** Рифат Мәхмүт улы; җәмәгать туклануы системасын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Содексо ЕвроАзия» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте шеф-повары **Рәсүлев** Мансур Насыйр улы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе өчен «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Фундаменталь медицина һәм биология институтының Биология югары мәктәбе Биология һәм педагогик белем үзәге зоология һәм гомуми биология кафедрасы мөдире **Сабиров** Рушан Мирза улы; республикада китапханә эшен үстерүгә һәм камилләштерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Аксубай авылара үзәк китапханәсе» район муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе директоры **Телешева** Ирина Анатольевна; театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Россия Федерациясе Театр әһелләре берлеге (Бөтенроссия театр җәмгыяте)» гомумроссия иҗтимагый оешмасы әгъзасы **Шәймәрданов** Роберт Шәйхил улы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм театр сәнгатен үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен «К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Харисов** Зөфәр Назыйм улы; республикада дәүләт яшьләр сәясәтен кертүләре өчен гамәлгә ашыруга зур өлеш «В.Г.Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты (Икътисад, идарә һәм хокук институты)» югары белем бирү хосусый мәгариф учреждениесенең беренче проректоры, фәнни эш буенча проректоры **Бикеев** Игорь Измаилович, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең социаль һәм тәрбия эше буенча проректоры **Межведилов** Ариф Магидинович **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

«Дәүләт химия продуктлары фәнни-тикшеренү институты» федераль казна предприятиесенең конструкторлык үзәге баш белгече **Азизов** Ингел Арифҗан улына, «Казан төгәл машиналар төзү заводы» фәнни-җитештерү берләшмәсе» федераль казна предприятиесенең автоматлар һәм ярымавтоматлар көйләүчесе **Воробьев** Сергей Викторовичка, «Дәүләт химия продуктлары фәнни-тикшеренү институты» федераль казна предприятиесенең ату коралларын кору өчен шартлаткыч матдә бүлеге баш белгече **Галиуллин** Илдар Генат улына, «Казан төгәл машиналар төзү заводы» фәнни-җитештерү берләшмәсе» федераль казна предприятиесе генераль директоры урынбасары – баш инженеры **Гасимов** Эрик Михайловичка, «Казан төгәл машиналар төзү заводы» фәнни-җитештерү берләшмәсе» федераль казна предприятиесенең автоматлар һәм ярымавтоматлар көйләүчесе **Герасимов** Владимир Николаевичка, «В.Б.Шнепп исемендәге үзәктән куучы һәм роторлы компрессорлар буенча фәнни-тикшеренү һәм конструкторлык институты» акционерлык җәмгыятенең җитештерү комплексы токаре **Игнатьев** Александр Георгиевичка, «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесенең 30 номерлы цехы баш механигы урынбасары **Хәмидуллин** Илнур Галимулла улына **«Татарстан Республикасының атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«СОРНАЙ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте автомеханигы (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Абдуллин** Дамир Сабир улына, «САРМАН» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең диспетчер-нормировщигы (Татарстан Республикасының Сарман районы) **Әхмәтшина** Сәрия Азат кызына, «П.В.Дементьев исемендәге агрофирма» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте бүлекчәсе идарәчесе (Татарстан Республикасының Чүпрәле районы) **Белялов** Җәмил Сәйфулла улына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең җитештерү-маркетинг бүлеге консультанты **Вәлиуллин** Халит Һидиятулла улына, «Дубрава» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механигы (Татарстан Республикасының Кайбыч районы) **Гәрәев** Исфат Гашыйгулла улына, «Сәйдәшев исемендәге авыл хуҗалыгы предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте бухгалтеры (Татарстан Республикасының Тукай районы) **Гарфутдинова** Фәйрүзә Наил кызына, «АККИРӘЙ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механигы (Татарстан Республикасының Чирмешән районы) **Гатиятов** Камил Әбүбәкер улына, «ЧИРМЕШӘНАГРО» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Гозәеров** Илшат Сәйфулла улына, «Дәүләтшин Җәмил Нәҗип улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы (Татарстан Республикасының Буа районы) **Дәүләтшин** Җәмил Нәҗип улына, «Чынлы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте инженер-технологы (Татарстан Республикасының Чүпрәле районы) **Ибраһимов** Илдус Фиркать улына, «П.В.Дементьев исемендәге агрофирма» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте бухгалтеры (Татарстан Республикасының Чүпрәле районы) **Калугина** Галина Александровнага, «Мөхәммәдиев Марат Мәсгут улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы (Татарстан Республикасының Әгерҗе районы) **Мөхәммәдиев** Марат Мәсгут улына, «Восток Зернопродукт» акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Мөхәммәтҗанов** Рәфкать Ахун улына, «Атабай» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте бухгалтеры (Татарстан Республикасының Лаеш районы) **Рахманова** Фәридә Мансур кызына, «Сәйдәшев исемендәге авыл хуҗалыгы предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте бухгалтеры (Татарстан Республикасының Тукай районы) **Сәгыйдуллина** Нәсимә Баһаветдин кызына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Мәдәният һәм сәнгатьне үстерүдәге мөһим казанышлары, күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге өчен «В.И.Качалов исемендәге Казан академия рус зур драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе сәнгать җитәкчесе – директоры **Славутский** Александр Яковлевич **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

***

Балалар тәрбияләүдәге һәм гаилә традицияләрен ныгытудагы казанышлары өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге буенча Идел буе районыннан җиде бала анасы **Максимова** Валентина Юрьевна, «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге буенча биш бала анасы **Медведева** Нина Викторовна **Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе, һөнәри һәм иҗтимагый эшчәнлектә югары казанышларга ирешүе өчен «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Яшьләр сәясәте, социаль мәсьәләләр һәм физкультура-спорт тәрбиясе системасын үстерү департаменты директоры **Виноградова** Юлия Владимировна, Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Моратов** Яшәр Габдулла улы, Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе, һөнәри һәм иҗтимагый эшчәнлектә югары казанышларга ирешүе өчен Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең неврология, нейрохирургия һәм медицина генетикасы кафедрасы мөдире **Якупов** Эдуард Закирҗан улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эксперт департаменты җитәкчесе **Савельев** Игорь Леонидовичка; Чаллы шәһәренең «НУР» яшьләр үзәге» муниципаль автоном учреждениесенең яшьләр белән эшләү буенча белгече **Кузнецова** Рәзилә Миннеәхмәт кызына, «Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Тәрбия һәм социаль эш идарәсе башлыгы **Ляукина** Гөлнара Альберт кызына **«Татарстан Республикасының атказанган яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗӘК САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ КАРАРЫ

24 ноябрь, 2021 ел Казан ш. № 162/1383

2021 елның октябрендә төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен раслау турында

Тиешле мәгълүматны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга бер календарь ае эчендә тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен билгеләү буенча Эш төркеменең «2021 елның октябрендә төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләре турында» 10 ноябрь, 2021 ел, № 94 карарын тикшергәннән соң, «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалында һәм радиоканалында яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 11 ноябрь, 2010 ел, № 35/392 карары белән расланган Төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы һәр сәяси партия эшчәнлеген бер календарь ае эчендә яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү тәртибенең VI бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе **карар бирә**:

1. 2021 елның октябрендә төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы һәр сәяси партия эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен (Эш төркеменең 10 ноябрь, 2021 ел, № 94 карарында урын алган) расларга.
2. «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖ тарафыннан гамәлгә куелган һәм эшләтелә торган «Татарстан – Яңа Гасыр» телевидениесе» төбәк телеканалының 2021 елның октябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген бер календарь ае эчендә тигез күләмдә яктырту турында «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалында яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законы таләпләрен үтәве турында бәяләмә чыгарырга.
3. «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖ тарафыннан гамәлгә куелган һәм эшләтелә торган «Татарстан – Яңа Гасыр» радиосы» – «Болгар» радиосы» радиопрограммасы» төбәк радиоканалының 2021 елның мартында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген бер календарь ае эчендә тигез күләмдә яктырту турында «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалында яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законы таләпләрен үтәве турында бәяләмә чыгарырга.
4. Бу карарны «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖгә, «Бердәм Россия» бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстандагы төбәк бүлегенә, «Россия Федерациясе Коммунистлар партиясе» сәяси партиясенең Татарстандагы төбәк бүлегенә җибәрергә.
5. Бу карарны бастырып чыгару өчен «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарына җибәрергә һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.
6. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рәисе урынбасары О.В. Сквордяковка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе А.С. Кондратьев

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе Секретаре Н.П. Борисова

Белдерү

ИЗВЕЩЕНИЕ О НЕОБХОДИМОСТИ СОГЛАСОВАНИЯ ПРОЕКТА МЕЖЕВАНИЯ

Кадастровым инженером Самоховым Александром Сергеевичем (420133, РТ, г. Казань, ул. Академика Лаврентьева, д. 11, пом. 1005; 6238322@mail.ru; тел.: 89178883476, № квалификационного аттестата 16-12-546) подготовлен проект межевания земельного участка, выделяемого в счет земельных долей из земельного участка с кадастровым номером 16:34:000000:296, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Рыбно-Слободский муниципальный район, территория паевого фонда СХК «Чукай». Заказчиком кадастровых работ является Залялов Алмаз Марсович (422650, РТ, Рыбно-Слободский район, пгт Рыбная Слобода, ул. Некрасова, д. 33, тел.: 89274129400). С проектом межевания можно ознакомиться с понедельника по пятницу с 9.00 до 17.00 ч. по адресу: 420133, РТ, г. Казань, ул. Академика Лаврентьева, д. 11, пом. 1005, тел.: 89178883476. При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок. Обоснованные возражения и предложения по доработке проекта межевания принимаются в письменном виде в течение тридцати дней со дня опубликования данного извещения по адресу: 420133, РТ, г. Казань, ул. Академика Лаврентьева, д. 11, пом. 1005.

Белми калмагыз!

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»ГА ЯЗЫЛУЧЫГА – МИНИ-ТРАКТОР

БҮЛӘКНЕ АЛУ ШАРТЛАРЫ

1 2022 елның беренче яртыеллыгына 6 айга «Ватаным Татарстан» газетасына язылырга.

2 Язылу квитанциясен безгә җибәрергә: «Ватсап» (89179270040) яки почта аша (420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт, «ВТ» газетасы редакциясе), яки электрон адреска (info@vatantat.ru).

БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН ТЕЛЕФОН: 8-917-927-00-40

Җиңүче жирәбә юлы белән ачыкланачак. Квитанцияләр 2022 елның 16 гыйнварына кадәр кабул ителә, жирәбә 20 гыйнвар көнне үткәреләчәк.

Акцияне оештыручы: «Ватаным Татарстан» газетасы ДБУ, акцияне уздыру вакыты 2021 елның 1 ноябреннән 2022 елның 15 февраленә кадәр. Тулырак мәгълүмат vatantat.ru сайтында.

УРАЛЕЦ ТОРГОВЫЙ ДОМ МЫ ПРОДАЁМ НАДЁЖНОСТЬ

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕСЕ – «УРАЛЕЦ» СӘҮДӘ ЙОРТЫ

- ✓ мини-тракторлар;
- ✓ барлык төр тракторлар өчен запас частьлар;
- ✓ җир эшкәртү, чәчү, җыйнау өчен асылмалы җиһазлар.

Казан ш., Мамадыш тракты, 35А; Чаллы ш., Казан проспекты, 252/1; Әлмәт ш., Советская урамы, 42А.

ТЕЛЕФОННАР: 8-927-465-12-94, 8-987-931-55-50

ГАЗЕТАГА ЯЗЫЛУ ЫСУЛЛАРЫ

1 ПОЧТА БҮЛЕКЧӘЛӘРЕНДӘ

2 ОНЛАЙН: vatantat.ru сайтындагы сылтама аша газетага язылу бик уңайлы һәм тиз. Программа үзе адымлап алып бара.

Әлеге QR-код ярдәмендә телефон аша газетага язылырга һәм акча түләргә мөмкин.

Сөенечле хәбәр!

2022 елның беренче яртыеллыгы өчен 6 айга язылу бәяләре

П2435 атнага бер, җомга килә ~~465 сум~~ 404,04 сум

П2409 Сишәмбе, чәршәмбе, җомга, шимбә килә ~~1000,92 сум~~ 859,08 сум

6–16 декабрь көннәрендә ташламалы бәяләр!

Реклама 16+

ДОГАДА БУЛЫЙК!

Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Салават Фәтхетдиновның соңгы елларда бакыйлыкка күчкән олпат шәхесләребезне искә алуларны оештыруына тәмам күнектек инде.

Концертларында да нәкъ менә бер бүлек Илһам Шакировка, Әлфия Авзалова, Шамил Закиров, Ирек Баһманов, Хәния Фәрхи, Хәмдүнә Тимергалиева, Роберт Миңнуллин, Әлфис Кыямов, Айдар Хафизов, Хәлим Җәләй, туганнарыдай якын күргән Ирек Миңнәхмәтов, Алсу Фәрдиевага һ.б. сердәш-фикердәшләренә багышлана. Заманында ул концертларына сәнгать әһелләренең байтагын кунак буларак сәхнәдә чыгыш ясарга да чакырды. Кунак дигәннәре шатлана-шатлана киләләр дә тамашачыга да, үзләренә дә бәйрәм ясыйлар, Салаватка исә өеп-өеп рәхмәтләр укыйлар. Әлеге күркәм гадәт, шөкер, хәзер дә дәвам итә. Халык Салаватның үзен көткән кебек үк кунагын да түземсезлек белән көтә.

Мәчеттә, нәкъ менә Казанның Мәрҗани мәчетендә әрвахлар рухына Коръән укыту, аш мәҗлесе үткәрү дә – аның теләк-нияте. Мәҗлескә иҗат әһелләре – җырчылар (әмма җырлаучылар түгел), театр артистлары, сатира-юмор осталары чакырулы. Күнегелгәнчә, Салаватның гаиләсе – балалары, кияүләре, оныклары да шушында. «Гадәттә без шәхесләребезнең өчесен, җидесен, кырыгын уздырабыз да тынычланып калабыз. Бу һич кенә дә бизи торган гамәл түгел, – ди Салават Фәтхетдинов. – Аларның халкыбызга күрсәткән игелекләрен һәрчак исебезгә төшереп торырга, онытмаска, яшь буынга да җиткереп барырга бурычлыбыз. Мөмкинлек, җай чыккан саен шәхесләребез рухына дога кылдырырмын, аш мәҗлесләре үткәрермен, дигән нәзерем бар. Менә шуны үтим».

Коръән ашында катнашучылардан кайберәүләрнең исем-фамилиясен язып узу да күп нәрсә хакында сөйли, дип беләм. Шунысы да мәгълүм булсын: исемлек елдан-ел үзгәреп, артып тора. Равил Шәрәфиев, Дания Нуруллина, Алсу Гайнуллина, Әсгать Хисмәт, Нурия Һашимова, Фәнис Мөсәгыйтов, Зөлфия һәм Җәвит Шакировлар, Филүс Каһиров, Альфред Якшимбетов, Илфат Шәехов, Ядкәр Хәбибуллин, ИлСаф, Роберт Закиров… Исемлекне шактый дәвам итәргә мөмкин. Чечен Республикасы башлыгының Татарстандагы вәкиле Асламбек Бердукаев та мондый очрашуларның бик изге гамәл булуына басым ясады, нык хуплавын, яклавын белдерде. «Халкыбызның «Үлгәннәрнең – каберен, исәннәрнең кадерен бел» дигән әйтеменә олы мәгънә салынган, – диде Мәрҗани мәчетенең имам-хатыйбы Мансур хәзрәт Җәләлетдинов. – Мәрхүмнәрнең гөнаһларын ярлыкауны да сорыйк. Алар бездән дога көтә». Шулай итеп, изге теләк, ният белән куллар догага күтәрелә. Салаватның үзенә Ходай Тәгалә әҗер-савапларын бирсен.

Теләп эшләгән эш – бүләк, мәҗбүрие – җәза, дигән халкыбыз. Яраткан җырчыбыз әлеге гамәлне бик теләп, яратып башкара, елның-елында үзенчәлеклерәк, истә калырлык итәргә омтыла. Максатына ирешә дә. «Бу гамәл мине рухи баета, күңелемә бетмәс-төкәнмәс тынычлык, илһам бирә». Монысы да – Салаватның табын янында әйткән сүзләре.

Габделбәр РИЗВАНОВ

КОВИД АЯКТАН ЕККАН

ПАНДЕМИЯ АРКАСЫНДА БАЛАЛАР ИМГӘНӘ

Көчләрен кая куярга белмиләр! Пандемия аркасында балалар арасында имгәнү, җәрәхәтләнү очраклары арткан. Һәрхәлдә, табиблар шулай ди. Республика балалар клиник хастаханәсенең травматология бүлеге мөдире Руслан Хәсәнов сүзләренә караганда, бүген аларга тәүлегенә 200ләп баланы алып киләләр икән. Шуларның кырыкка якыны стационарга салына.

Түзәргә ярамый

«Соңгы бер-ике елда бездә балалар арасында җәрәхәтләнү, имгәнү очраклары бик нык артты. Бу аңлашыла да. Күңел ачу өчен оештырылган барлык махсус мәйданчыклар да ябык. Балалар көчләрен кая куярга белми аптырый. Кирәкмәгән җиргә менәләр, ярамаганны эшлиләр», – диде табиб матбугат очрашуында. Әле шушы көннәрдә генә хастаханәгә өстенә телевизор ауган бер кызны алып килгәннәр. Баланың баш мие селкенгән, күкрәк читлеге җәрәхәтләнгән. «Балаларны бер мизгелгә дә игътибарсыз калдырырга ярамый. Аларның энергиясе күп, ата-аналар шуны истән чыгармасын иде», – ди Руслан Хәсәнов.

Белгеч фикеренчә, кыш көне балалар арасында иң еш күзәтелә торган имгәнү, җәрәхәтләнү очраклары да, нигездә, ата-аналарның игътибарсызлыгы аркасында килеп чыга. Кыш башланырга да өлгермәде, травматология бүлегенә тау чаңгысы базасында ял иткәндә имгәнгән балаларны китерә башлаганнар. Күбесенең оча, бот, тубык сөякләре сынган. «Бүген ата-ана тормыш куа. Шуңа күрә балага еш кына тиешле игътибар бирелми. Бүген балага кайда ничек йөрергә кирәклеген аңлатып торучы да юк», – ди Руслан Хәсәнов.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Елның-елында табиблар иң куркыныч күңел ачу чарасы дип атаган «ватрушка»да шуу сезоны башлангач, балалар арасында имгәнүчеләр саны тагын да артырга мөмкин дип борчыла белгечләр. Узган елларда шушы куркыныч җайланма аркасында үлем-китем белән тәмамланган аянычлы очраклар да күзәтелде. «Анда шуганда бала ныклап тотына алмый. Шуңа күрә «ватрушка»да шуу еш кына баланың оча, муен сөяге җәрәхәтләнү белән тәмамлана. Үлем-китемгә китергән очраклар да булды. Чана белән азмы-күпме идарә итеп була әле. Аны аяк белән туктатып калырга да, кирәк икән, янга аварга да мөмкин. Шуңа күрә «ватрушка»да махсус җайлаштырылган урыннарда гына шуарга кирәк», – ди Руслан Хәсәнов.

Табиб балалар арасындагы имгәнү очракларын катлауландырган тагын бер җитди сәбәпне атый. Ул да булса, балаларның имгәнгән очракта да кай җире авыртуын әйтмәве. Зарланмагач, ата-ана да аны-моны абайламыйча кала. «Әгәр бала белән урамнан кергәч, ул авыртудан зарланса, хәле бер сәгатьтән соң да рәтләнмәсә, имгәнгән урында кара көйгән тап пәйда булса, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Бала үзенә хас булмаганча йокымсырап йөрсә, нейрохирургка баруыгыз хәерле. Сабыйның баш мие селкенгән булырга мөмкин», – ди белгеч.

Аяк киемендә дә хикмәт

Кышкы чорда өлкәннәр арасында иң еш күзәтелгән җәрәхәтләнү очраклары дип белгечләр умрау һәм бот сөяге сынуны атый. Травматология бүлегенә килеп ирешкән барлык мөрәҗәгатьләрнең 10–15 проценты нәкъ менә шуларга туры килә. 7 номерлы шәһәр хастаханәсенең травматология бүлеге мөдире Альберт Галимов сүзләренә караганда, мондый имгәнүләр иң катлаулылардан санала. Алардан соң тернәкләнеп аякка басу өчен дә шактый вакыт таләп ителә. Соңгы арада республика халкы, нигездә, бозлавыкта таеп егылып имгәнә башлаган.

Кышкы чорда егылудан саклану өчен, иң беренче чиратта, таймый торган, нык табанлы аяк киеменнән йөрергә киңәш итә Альберт Галимов. Карлыбозлы юлдан атлап йөрүнең дә рәте бар. «Кыш көне ашыкмыйча, вак-вак атлап йөрүдән дә яхшысы юк. Аяклар бераз бөгелә төшсә яхшырак», – ди. Үзе кышкы күңел ачу төрләреннән чаңгы шууны үз итә икән. Чаңгыда таудан төшкәндә, карның тыгызлыгына карап, төрле алымнар кулланып хәрәкәтләнергә киңәш итә. «Тимераякта шуганда да мөгез чыгарырга кирәкми. Өлкәннәр дә, балалар да түгәрәк буйлап бөтен куркынычсызлык кагыйдәләрен саклап хәрәкәт итәргә тиеш», – ди ул.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

РӘЙДӘ ИЛЬИНА:

«КУРЧАКЛАР ДӨНЬЯСЫНДА ЯШИМ»

Аның курчаклары арасында бай сәүдәгәрләр, ханбикә Сөембикә, Алтынчәч образлары да, кулларына чәкчәк, «Казан сөлгесе» тоткан татар кызлары да, гармунчы егетләр дә бар. «Урман арты» мәдәният үзәгендә клуб берләшмәсе, «Мозаика» декоратив-гамәли иҗат остаханәсе җитәкчесе Рәйдә Ильина бүген «Авыл яшьләре» сериясен иҗат итә. Мондый матурлыкны тудыру өчен курчаклар белән җенләнергә кирәкме?

Рәйдә Ильина – Кайбыч кызы. Борындык авылында алты балалы матур гаиләдә тәрбияләнгән ул. Тирә-якка балта остасы булып танылган әтисен – «алтын куллы Фәһим», әнисе Рәшидәне туганнары «матур апа», «алма апа» дип йөрткәннәр. Әтисенең үзе кисеп, сырлап ясаган тәрәзә кашагаларын күреп, әнисенең бер сандык чигүле кул эшләнмәләренә сокланып үскән кыз бит ул! Матурлыкка омтылыш бала вакыттан ук сеңгән, димәк. Белгечлеге буенча – рәссам-бизәүче.

– Әни безгә күлмәкләрне тегү машинасында текте. Әби тегүчегә барып, яңа күлмәкләргә заказ бирергә ярата иде. Үземнең мамык тутырып эшләгән курчагымны хәтерлим. 7 нче сыйныфта укыганда апаларым Илүсә, Миләүшә белән өчебезгә дә яшел төсле ситсы күлмәкләр теккән идек, – дип искә алды Рәйдә ханым беренче теккән күлмәген.

Курчаклар дөньясына кереп китсәң, тиз генә чыга алмыйсың. Рәйдә Ильина һәр хезмәте турында тәмләп, бик озаклап сөйли ала. Кечкенә генә сувенир татар кызчыклары булсынмы, күннән эшләнгәнеме – барысын да яратып эшли. Казан татарларының төрле гасырларга караган костюмлы зур курчаклар да ясый. Дөресрәге, киендерә, алар – әзер курчаклар. Затлы киемле шәһәр мәдәниятенә караган бай сәүдәгәр хатыннары, гүзәл ханбикә Сөембикә образларын курчакларда бик күп гәүдәләндергән. Аның курчакларга исемнәр бирү гадәте юк. Аларда ниндидер холык-фигыльләр дә күрми, җаннары бар дип тә уйламый.

– Кызлар «көязрәктер» инде. Егетләрне киендерү авырмы, әллә кызларныммы? – дип сорыйм остаздан.

– Кызлар көязрәк шул. Аларның киемнәре дә озаграк «туа». Ясаган курчакларның саны 100гә җитәдер. Күбрәк XVIII–XIX гасыр Казан татарларының бай хатын-кызларына охшап тудырыла. Узган ел, республиканың 100 еллыгына багышлап, Татарстанда яшәүче төрле халыкларның, әйтик, мари, чуаш, керәшен, урыс һәм башка милли курчаклар күргәзмәсен оештырдык. Аны яшьләр белән бергәләп ясадык, – ди белгеч.

Курчаклары кемне генә кызыктырмый! 2018 елда беренче ике курчагын Аккош күлендә узган Сабантуйда Мәскәү егете сатып алган. Курчаклары илнең төрле төбәкләренә таралган. Кайберләре Башкортстан, Чиләбе якларында, хәтта чит илләрдә дә «яши». Узган ел Алтынчәч образын бүләккә дип Израильгә җибәргәннәр. Парлы курчакларын да бик яраталар икән, хәтта заказга бер зур гаилә дә эшләгән. Курчаклар турында матур сүзләр генә ишетергә туры килә аңа. Кул эшләрен 200дән 2 мең сумга кадәр тәкъдим итә. Хезмәтләремне ашыгып ясамыйм, тулы образ тудыру өчен нәрсәдер җитеп бетмәсә, кайвакыт айлар буе сузылырга мөмкин, ди.

Иң яраткан курчаклары – авыл кызлары. Соңгы вакытта авыл мәдәниятенә караган «Авыл яшьләре» дигән сериядәге кызлар, егетләр образларын булдыру буенча эшли. Нәкъ авылча, татарча киемнәрдән – вак чәчәкле ситсыдан тегелгән бала итәкле күлмәкләрдән, ак батист яулыклардан, чигүле канатлы алъяпкычлардан, бизәкле читекләрдән, озын толымнарына чыңлаган чулпылар таккан чибәр авыл кызлары һәм матур егетләр.

– Матур-матур татар курчакларын ясаганда, төрле-төрле образлар тудырганда, әлбәттә, милли горурлык хисләрен тоям. Мәдәният өлкәсендә эшләвемә – 28 ел. Хезмәтем, яраткан шөгылем белән дә милләтемә хезмәт итәм дип уйлыйм. Ун ел элек балалар өчен «Мозаика» остаханәсен булдырган идек. Бар белгәнемне алар белән бүлешәм. Россиянең традицион халык кәсепләрен, һөнәрчелеген өйрәнәбез. Төрле кул эшләнмәләрен ясыйбыз: чигәбез, тегәбез, бәйлибез. Декоратив-гамәли сәнгатьнең традицион һәм заманча юнәлешләрендә эшлибез. Татар хатын-кызларының милли костюм комплексына кергән изүләр, хәситәләр ясарга, төрле баш киемнәрен тегәргә өйрәнәбез. Балаларда халкыбызның борынгыдан килгән кул эшләренә, сәнгатенә мәхәббәт, омтылыш һәм теләк уята алсам, мин бик бәхетле. Олылар өчен «Яшәү дәрте» остаханәсе булдырдык. Миллилек һәрберебезнең канына сеңгән булырга тиеш дип уйлыйм, – ди Татарстанның Һөнәрчелек палатасы әгъзасы Рәйдә ханым.

Сәрия МИФТАХОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.

Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7404 данә
Гомуми тираж – 17211 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 373

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+